**ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ЗАКУПКАМ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ САТЫП АЛУЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**05.08.2021** № **04-05-94**

Казан шәһәре

Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетының 2016 нчы елның 12 нче апрелендә кабул ителгән 04-14-49 номерлы “Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетында норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый акт проектларының ришвәтчелеккә каршы экспертизасы турында”гы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Ришвәтчелеккә каршы эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген арттыру максатыннан б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетының 2016 нчы елның 12 нче апрелендә кабул ителгән 04-14-49 номерлы “Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетында норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый акт проектларының ришвәтчелеккә каршы экспертизасы турында”гы боерыгына (Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетының 2017 нче елның 24 нче мартында кабул ителгән 04-14-40 номерлы, 2019 нчы елның 12 нче августында кабул ителгән 04-05-94 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче һәм 3 нче пунктларны үз көчләрен югалткан дип исәпләргә;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетында норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый акт проектларының ришвәтчелеккә каршы экспертизасын үткәрү тәртибенең 2.1 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2.1. Актларның һәм акт проектларының ришвәтчелеккә каршы экспертизасын Дәүләт комитетында ришвәтчелеккә каршы экспертиза үткәрү

өчен җаваплы булган хезмәт урынындагы кеше үткәрә (алга таба – хезмәт урынындагы кеше). Хезмәт урынындагы кеше Дәүләт комитеты рәисенең боерыгы нигезендә билгеләнә. Әлеге хезмәт урынындагы кеше шулай ук Дәүләт комитетында ришвәтчелеккә каршы экспертизага тапшырылган норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый акт проектларының исәбе алып барыла торган журналны (алга таба – Журнал) тутыру өчен дә җаваплы (әлеге Тәртипнең 1 номерлы кушымтасы).

2. Элеге боерыкның үтәлешен үзем контрольдә тотачакмын.

Рәис Р.Н.Сабиров